КИТАПХАНӘ ХӘБӘРЛӘРЕ
Фәнни-гамәли журнал

Научно-практический журнал
2 (34) 2012
БИБЛИОТЕЧНЫЙ ВЕСТНИК

Журналга кушымта

Чирек гасыр сәнгатькә хезмәттә...

(Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең сәнгать бүлегенә 25 ел: 1987-2012 еллар)

Приложение к журналу

Четверть века служения музам...

(25 лет отделу искусств Национальной библиотеки Республики Татарстан: 1987–2012 гг.)

Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең
сәнгать бүлеге урнашкан бина – Казан шәһәре, Театр урамы, 5 йорт
Здание, в котором расположен отдел искусств Национальной библиотеки
Республики Татарстан – г. Казань, ул. Театральная, дом 5

Чирек гасыр сәнгатькә хезмәттә...

(Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең сәнгать бүлегенә 25 ел: 1987-2012 еллар)

ТАТАРСТАН МИЛЛИ КИТАПХАНӘСЕНЕҢ СӘНГАТЬ БҮЛЕГЕ 2012 ЕЛДА ҮЗЕНЕҢ ЧИРЕК ГАСЫРЛЫК ЮБИЛЕЕН БИЛГЕЛӘП ҮТӘ. ШУШЫ ЕЛЛАР ЭЧЕНДӘ БҮЛЕКНЕҢ КЫСКАЧА ТАРИХЫНА, ИРЕШКӘН УҢЫШЛАРЫНА ҺӘМ КАЗАНЫШЛАРЫНЫҢ ИҢ ӘҺӘМИЯТЛЕ ДИП ТАБЫЛГАННАРЫНА КҮЗ САЛЫП ҮТИК.

1987 елда Казан шәһәре үзәкләштерелгән китапханәләр челтәре Үзәк китапханәсенең ноталы басмалар һәм музыкаль әсәрләр бүлеге нигезендә оештырылган бүлек башта Печән базары мәчетендә (хәзер «Нурулла» мәчете; Казан, Мәскәү урамы, 74 йорт) урнаштырыла. Эшчәнлеге дәверендә бүлеккә ике тапкыр күченергә туры килә һәм, әйтергә кирәк, бу күченүләр бүлек өчен файдага була. 1989 елдан 1999 елга кадәр бүлек Карл Маркс урамындагы 36 йортта урнашкан булса, 1999 елдан хәзерге көнгә кадәр Театр урамындагы 5 йортта эшли.

Сәнгать бүлегенең 1989 елда шәһәр үзәгенә күченүе, Н.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт

Четверть века служения музам…

(25 лет отделу искусств Национальной библиотеки Республики Татарстан: 1987–2012 гг.)

В 2012 ГОДУ ОТДЕЛУ ИСКУССТВ НАЦИОНАЛЬНОЙ БИБЛИОТЕКИ РТ ИСПОЛНИЛОСЬ ЧЕТВЕРТЬ ВЕКА. ИСТОРИЯ ОТДЕЛА БОГАТА ЯРКИМИ СОБЫТИЯМИ И ДОСТИЖЕНИЯМИ, О НАИБОЛЕЕ ЗНАЧИМЫХ ИЗ КОТОРЫХ МЫ ХОТЕЛИ БЫ РАССКАЗАТЬ.

Созданный в 1987 году на базе нотно-музыкального отдела Центральной библиотеки Централизованной библиотечной системы г. Казани, отдел первоначально располагался в здании мечети «Сенного базара» (ныне – мечеть «Нурулла», ул. Московская, 74). За время своего существования отдел дважды, и очень удачно, менял свое месторасположение. С 1989 по 1999 гг. отдел располагался по ул. К. Маркса, д. 36, а с 1999 г. и по сегодняшний день – на ул. Театральной, д. 5.

Переезд в 1989 году в центр города, расположение в непосредственной близости от Казанской государственной консерватории им.

Сәнгать бүлеге мөдире Татьяна Никитична Рудик
Заведующая отделом искусств Татьяна Никитична Рудик

Бүлек хезмәткәрләре: Т.Н. Рудик, Е.Ю. Артамонова, М.В. Липачева, Ә.М. Мөхәммәтҗанова
Сотрудники отдела: Т.Н. Рудик, Е.Ю. Артамонова, М.В. Липачева, А.М. Мухаметзянова

Сәнгать бүлеге мөдире Т.Н. Рудик һәм әйдәп баручы китапханәчеләр: О.В. Малафеева һәм Ә.М. Мөхәммәтҗанова
Заведующая отделом искусств Т.Н. Рудик, и ведущие библиотекари О.В. Малафеева и А.М. Мухаметзянова

Сәнгать бүлегенең баш китапханәчесе М.В. Липачева
Главный библиотекарь отдела искусств М.В. Липачева

консерваториясенә, И.Әүхәдиев исемендәге Казан музыка училищесына (көллиятенә), М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театрына, С. Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залына бик якын урнашуы студентлар, музыкантлар, музыка һәм сынлы сәнгать укытучылары, сәнгать сөючеләр өчен бик тә уңайлы була һәм ул зур популярлык казана. Бүлектән файдаланучылар саны елына 2000гә кадәр җитә.

Сәнгать бүлегенең штаты зур түгел – биш кешедән генә тора. Чирек гасыр буена ул үзгәрми диярлек, чөнки биредә үз эшенә чын күңелдән бирелгән фидакяр шәхесләр эшли. Бүлек оешканнан бирле аның җитәкчесе – Татьяна Никитична Рудик, Марина Вячеславовна Липачева 24 елдан артык эшли, Әлфия Мәхмүт кызы Мөхәммәтҗанованың һәм Елена Юрьевна Артамонованың да биредә эшли башлауларына тиздән 20 ел була. Шулай ук бүлектә Альбина Бинарис кызы Галимбәкова да 20 елга якын эшләде, ул хәзер китапханәдә башка бер бүлекне җитәкли. Әле 2 елдан артык кына эшләсә дә, Ольга Владимировна Малафеева тиз арада эшнең серләренә төшенде, коллективны үз итте.

Сәнгать бүлегенең үз уку залы бар, музыкаль язмалар тыңлау, фильмнар карау, белем бирү программаларын үзләштерү, Интернетка кереп, үзеңә кирәкле мәгълүматларны табу өчен махсус җиһазландырылган урыннар да җитәрлек, кыскасы, бөтен шартлар да тудырылган.

Н.Жиганова, Казанского музыкального училища (колледжа) им. И.Аухадеева, Татарского государственного академического театра оперы и балета им. М.Джалиля, Большого концертного зала им. С.Сайдашева сделало отдел искусств чрезвычайно популярным среди студентов, музыкантов, учителей изобразительного искусства, музыки и любителей искусства. Отдел обслуживает около 2000 пользователей ежегодно.

Штат отдела искусств – 5 человек. Все 25 лет костяк сотрудников остается неизменным. Со дня основания отдел искусств возглавляет Рудик Татьяна Никитична, 24 года трудится Липачева Марина Вячеславовна, около 20 лет составляет трудовой стаж в отделе Мухаметзяновой Альфии Махмутовны и Артамоновой Елены Юрьевны, около 20 лет трудилась в отделе и ушла на повышение Галимбекова Альбина Бинарисовна, более 2 лет назад органично вписалась в коллектив Малафеева Ольга Владимировна.

Отдел искусств работает в режиме читального зала, имеет специально оборудованные места для прослушивания музыкальных записей, просмотра фильмов и образовательных программ, работы в Интернете.

Мы гордимся тем, что среди наших читателей – видные деятели искусства Республики Татарстан: композитор Рашид Калимуллин, музыковеды Георгий Кантор, Аида Алмазова, преподаватели творческих вузов г. Казани Диляра Давлетшина и Вячеслав Булгаков, музы-

Бүлекнең даими укучылары арасында Татарстанның күренекле сәнгать әһелләре: композитор Рәшит Кәлимуллин, музыка белгечләре Георгий Кантор, Аида Алмазова, Казандагы иҗади югары уку йортлары укытучылары Диләрә Дәүләтшина, Вячеслав Булгаков, музыкантлар Рэм Урасин һәм Лариса Маслова, җырчылар Лидия Әхмәтова, Альбина Шаһиморатова, Алексей Тихомиров, Михаил Казаков һәм башкаларның булуы белән без горурланабыз. Җырчылар Эмиль Җәләлетдинов, Юлия Җиһаншина, музыка белгече Гүзәл Юнысова белән бүлекне күпьеллык иҗади дуслык бәйли. Бүлекнең шәрәфле укучылары – композиторлар Леонид Любовский, Рәшит Абдуллин, музыка белгече Светлана Захарова, опера сөючеләр клубы президенты Ольга Иглина.

Китапханәнең бәһасе, конкурентлыкка сәләте, үзенә тарту көче, иң беренче чиратта, аның фондларының составы белән билгеләнә. Татарстан һәм татар халкы сәнгате тарихына караган документларны, классик һәм хәзерге заман сәнгате материалларын туплау фондларны оештыруда төп юнәлеш булып тора.

Оешкан вакытында Казанның Үзәк китапханәсеннән мирас булып бары тик ноталар һәм грампластинкалар гына күчкән булса, үсеш дәверендә Татарстан Милли китапханәсенең сәнгать бүлеге фондларын тулыландыру белән генә чикләнмәде, ә бәлки, төп файдаланучылар төркемнәре ихтыяҗларын исәпкә алып, фондны максатчан туплау юлы белән андагы документларның төрләрен дә арттырды. Хәзерге көндә сәнгать бүлеге фондында 46 меңнән артык документ саклана, алар арасында китаплар да, альбомнар да, ноталар да, электрон басмалар да, аудио-, видеоязмалар да, грампластинкалар да бар.

Фондларны оештыру һәм туплауның хәзерге вакыттагы төп бурычы – татар композиторлары әсәрләренең һәм татар халык көйләренең, классик (рус һәм чит ил) музыкаль әсәрләрнең тулы электрон җыелмасын барлыкка китерү.

Карточкалы һәм электрон каталог һәм картотекалар системасы күп юнәлешле эзләнүләр алып барырга һәм

канты Рэм Урасин и Лариса Маслова, певцы Лидия Ахметова, Альбина Шагимуратова, Алексей Тихомиров и Михаил Казаков, а также многие другие. Многолетняя творческая дружба связывает наш отдел с певцами Эмилем Заляльдиновым, Юлией Зиганшиной, музыковедом Гузель Юнусовой. Почетными читателями отдела являются композиторы Леонид Любовский, Рашид Абдуллин, музыковед Светлана Захарова, президент клуба любителей оперы Ольга Иглина.

Ценность библиотеки, ее конкурентоспособность и привлекательность определяются, в первую очередь, составом ее фондов. Приоритетными направлениями в формировании фондов отдела являются комплектование документами по истории искусства Татарстана и татарского народа, классическому и современному искусству.

Унаследовав от Центральной библиотеки на этапе создания лишь ноты и грампластинки, отдел искусств Национальной библиотеки Республики Татарстан за время своего развития не только увеличил численность фондов, но и добился путем целенаправленного комплектования изменения его типо-видового состава с учетом запросов основных групп пользователей. В настоящее время фонд отдела искусств составляет более 46 тыс. документов, среди которых – книги, ноты, электронные издания, грампластинки.

Основная задача в формировании фондов на современном этапе – создание полной коллекции





сәнгать бүлеге фондын тулысынча күзалларга мөмкинлек бирә. Бүлектә китапларның, ноталарның, төрле форматтагы мәгълүмат йөрткечләргә теркәлгән музыкаль язмаларның һәм видеофильмнарның алфавитлы һәм систематик каталоглары алып барыла. Музыкаль язмаларны композиторларның, башкаручыларның, сүзләр авторларының алфавит күрсәткечләре ярдәмендә дә эзләп табарга була.

Фондларны ретроконверсияләү эше дә бара. Ноталар фондын ретроконверсияләү инде тәмамланып килә. Файдаланучылар хәзер үзләренә кирәк булган ноталар турындагы мәгълүматларны Милли китапханәнең электрон каталогыннан таба алалар. 2013 елда бүлек грампластинкаларны ретроконверсияләүнең технологик тәртибен эшләүне һәм гамәлгә кертүне планлаштыра. Беренче чиратта татар композиторларының музыкаль язмалары мондый эшкәртүне узачак һәм, нәтиҗәдә, китапханә сайтына куелган мәгълүматлар аша теләгән һәркем әлеге фондның составы белән таныша алачак.

Сәнгать бүлегенең белешмә-библиографик эшчәнлегендәге иң зур казанышлары – 2005 елда дөнья күргән «Җырларда яши Казан» библиографик күрсәткече һәм Татарстан композиторлары иҗатына багышланган, зур популярлыкка ирешкән электрон белешмәлекләр.

«Җырларда яши Казан» библиографик күрсәткече (фәнни мөхәррире – А. С. Нурмөхәммәтова) 95 җыр турындагы мәгълүматны үз эченә ала. Башкалабызның 1000 еллыгына багышлап нәшер ителгән әлеге күрсәткеч бүген

музыкальных записей татарских композиторов и татарской народной музыки, классической (русской и зарубежной) музыки на электронных носителях.

Система каталогов и картотек (карточных и электронных) позволяет вести многоаспектный поиск и полностью раскрывает фонд отдела искусств. В отделе ведутся алфавитные и систематические каталоги книг, нот, музыкальных записей и видеофильмов на носителях всех форматов. Для музыкальных записей возможен поиск по алфавиту композиторов, исполнителей, авторов слов.

В отделе ведется работа по ретроконверсии фондов. В настоящее время заканчивается ретроконверсия нотного фонда. Пользователи уже сейчас могут получить информацию о наличии необходимых нот по электронному каталогу Национальной библиотеки Республики Татарстан. В 2013 году отдел искусств планирует разработать и внедрить технологическую схему ретроконверсии грампластинок. В первую очередь ее пройдут музыкальные записи татарских композиторов, что позволит всем желающим познакомиться с составом этой части фонда на сайте Национальной библиотеки Республики Татарстан.

В справочно-библиографической деятельности большим достижением отдела искусств является выпуск библиографического указателя «В песнях живет Казань» (2005 г.) и популярных электронных справочников, посвященных творчеству композиторов Татарстана.

Библиографический указатель «В песнях живет Казань» (научный редактор А.С.Нурмухаметова) содержит сведения о 95 песнях. Приуроченный к 1000-летию нашего города, он и по сей день вызывает интерес у пользователей библиотеки. Указатель занял 1 место на конкурсе научных работ сотрудников Национальной библиотеки Республики Татарстан.

Популярные электронные справочники, посвященные творчеству композиторов Республики Татарстан – совместный проект информационно-библиографического отдела и отдела искусств – часть общей коллекции Национальной библиотеки Республики Татарстан

дә кулланучыларда зур кызыксыну уята. Шуңа күрә, ТР Милли китапханәсе хезмәткәрләренең фәнни эшләре конкурсында аның беренче урынга лаек булуы гаҗәп түгел.

Мәгълүмат-библиография һәм сәнгать бүлекләренең уртак хезмәте нәтиҗәсендә барлыкка килгән, композиторларыбыз иҗатын чагылдырган популяр электрон белешмәлекләр – ТР Милли китапханәсе туплый торган, «Татарстан мәдәниятенең күренекле эшлеклеләре» дип исемләнгән гомуми коллекциянең бер өлеше. 2010–2012 елларда китапханә сайтында Сәлих Сәйдәшев, Нәҗиб Җиһанов, Рөстәм Яхин, Леонид Любовский, Мансур Мозаффаров иҗатлары турындагы белешмәлекләр урын алды. Сәнгать бүлегенең ниятләре зурдан – алдагы биш ел дәвамында ул Татарстанның классик һәм хәзерге заман композиторлары иҗатын яктырткан белешмәлекләр төзү эшен тәмамлап, булганнарын тулыландырып, Интернетка урнаштырырга уйлый.

Бүлекнең күпьеллык фәнни эшчәнлеге нәтиҗәсе итеп тагын бер саллы хезмәтне күрсәтмичә мөмкин түгел. 2010 елда дөнья күргән «Татарстанның музыкаль мирасы» библиографик күрсәткече милли ноталар репертуары төзүнең нигезе булып та саналырга хаклы. Ул (фәнни мөхәррире – А.С.Нурмөхәммәтова) 1928-2000 елларда басылып чыккан һәм Татарстанның эре китапханәләре фондларында сакланган 811 ноталы басма турындагы мәгълүматларны туплаган. 2010 елда әлеге күрсәткеч ТР Милли китапханәсе хезмәткәрләренең фәнни эшләре конкурсында беренче урынны алды. Күрсәткечне тулыландыру эше дәвам итә, аның киләсе чыгарылышы 2000-2010 еллар арасында нәшер ителгән ноталы басмалар турында мәгълүмат бирәчәк.

Бүлек эшчәнлегенең тагын бер мөһим юнәлеше – мәгърифәтчелек. Үткәрелә торган күптөрле чаралар системасы укучыларның төрле төркемнәрен күз уңында тота:

- Традицион китап (документлар) күргәзмәләре файдаланучыларның киң даирәсенә тәгаенләнә. Бер ел эчендә куела торган күргәзмәләр, гадәттә, гомуми исем астында бер циклга берләштерелә. Мәсәлән, 2012 елда «Иҗат. Мавыгу. Ял вакыты» дигән күргәзмәләр циклы оештырылды;
- Әдәбият һәм сәнгать белән кызыксынучыларны китапларга презентацияләр үткәрү җәлеп итә;

«Выдающиеся деятели культуры Республики Татарстан». В 2010 – 2012 гг. были подготовлены и размещены на сайте Национальной библиотеки Республики Татарстан популярные электронные справочники, посвященные творчеству Салиха Сайдашева, Назиба Жиганова, Рустема Яхина, Леонида Любовского, Мансура Музафарова. Отдел искусств планирует в течение 5 лет завершить создание коллекции справочников, представив творчество композиторов-классиков и современных композиторов РТ в Интернете.

Результатом многолетней научной деятельности отдела искусств является выпуск библиографического указателя «Музыкальное наследие Татарстана» (2010 г.), который рассматривается нами как основа создания репертуара национальных нот. Библиографический указатель (научный редактор А.С.Нурмухаметова) содержит сведения о 811 экз. нотных изданий, выпущенных в 1928-2000 гг., имеющихся в фондах крупнейших библиотек Республики Татарстан. В 2010 году указатель занял 1 место на конкурсе научных работ сотрудников Национальной библиотеки Республики Татарстан. Работа над указателем продолжается. Следующий его выпуск будет включать сведения о нотных изданиях 2000-2010 гг.

Важнейшим направлением деятельности отдела является просветительская работа. Сложившаяся система мероприятий предусматривает мероприятия для различных читательских групп:

- на широкие читательские круги рассчитаны традиционные выставки документов. Обычно выставки внутри года объединены в один цикл с общим названием. Так, в 2012 году для пользователей отдела был подготовлен цикл выставок «Творчество. Увлечения. Досуг»;
- специалистов в области культуры и искусства привлекают презентации книг;
- для учителей музыки и изобразительного искусства сотрудники отдела готовят Дни информации, которые включат выставки документов и обзоры литературы;
- для любителей музыки с 2000 года проводятся заседания видеосалона «Путешествие в мир оперы» и музыкальной гостиной «Музыка в потоке времени». В 2000-2010 гг. было проведено 46 заседаний видеосалона и 48 встреч в музыкальной гостиной. В разные годы

Туган як Сәнгате
Искусство родного края
Наследие веков
Искусство Древней Булгарии

ПРЕКРАСНОЕ СВОИМИ РУКАМИ
В помощь рукодельницам

Рәссам булырга телим!
Хочу быть художником
Корабли

Калейдоскоп стилей в мире моды

Сәнгать һәм мәгариф
Искусство и образование

РАЗНЫЕ ВЕКА
ТӨРЛЕ ДӘВЕРЛӘРДӘ КОНКУРЕШ ҺӘМ МАВЫГЫЛАР

ЛАНДШАФТЫ ДИЗАЙН СЕРЛӘРЕ
СЕКРЕТЫ ЛАНДШАФТНОГО ДИЗАЙНА

ОРНАМЕНТ-
ЧОР ҮЗЕНЧӘЛЕГЕ
ОРНАМЕНТ-
ПОЧЕРК ЭПОХИ

МИР
ХУДОЖЕСТВЕННОЙ
ФАНТАЗИИ
Народные промыслы России

Рәссам булырга телим!
Хочу быть художником!

Музыка
дөньясы
Мир
музыки

ЙӨРТ
ЗИННӘТЛӘУ:
ӨСЛУБЛӘР
ТАРИХЫ
УБРАНСТВО
ДОМА:
ИСТОРИЯ
СТИЛЕЙ

Россия Федерациясенең атказанган артисты, Татарстан Республикасының халык артисты Эмиль Җәләлетдинов белән очрашу кичәсе (2009 ел)
Вечер-встреча с заслуженным артистом РФ, народным артистом РТ Эмилем Заляльдиновым (2009 г)

- Музыка һәм сынлы сәнгать укытучылары өчен бүлек хезмәткәрләре документлар күргәзмәләрен һәм китап күзәтүләрне эченә алган Мәгълүмат көннәре уздыралар;
- Музыка сөючеләр өчен 2000 елдан башлап «Опера дөньясына сәяхәт» дигән видеосалон утырышлары һәм «Музыка вакыт агышында» дигән музыкаль кунакханә кичәләре үткәрелә. 2000-2010 елларда видеосалон 46 утырыш, ә музыкаль кунакханә 48 очрашу оештыргостями мероприятий были Мунира Булатова, Венера Ганеева, Галина Ластовка, Юрий Галявинский, Эдуард Трескин, Эмиль Заляльдинов, Юлия Зиганшина, Леонид Любовский и многие, многие другие замечательные артисты;
- для привлечения новых читателей из числа студентов и школьников проводятся Дни открытых дверей. Составной частью Дней открытых дверей является экскурсия по главному зданию Национальной библиотеки Республики

Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, композитор, Казан дәүләт консерваториясе профессоры, Россия Федерациясенең Дәүләт премиясе лауреаты һәм Милли китапханәнең якын дусты Леонид Любовский белән очрашу кичәсе (2010 ел)
Вечер-встреча с композитором, заслуженным деятелем искусств РТ и РФ, профессором КГК, лауреатом Государственной премии РФ и другом Национальной библиотеки Леонидом Любовским (2010 г)

Татарстан Республикасының халык артисты Мөнир Якупов белән «Раштуа тылсымы» исемле музыкаль-тематик кичәдә очрашу (2012 ел)
Музыкально-тематический вечер-встреча с народным артистом РТ Муниром Якуповым «Волшебство Рождества» (2012 г)

Казан дәүләт консерваториясе профессоры Галина Ластовка белән очрашу (2012 ел)
Вечер-встреча с профессором КГК Галиной Ластовкой (2012 г)

Россия Федерациясенең атказанган артисты, Татарстанның һәм Каракалпакстанның халык артисты Юрий Борисенко һәм Казан дәүләт консерваториясе профессоры Юзефина Сокольская белән очрашу (2012 ел)
Вечер-встреча с заслуженным артистом РФ, народным артистом РТ и Каракалпакии Юрием Борисенко и профессором КГК Юзефиной Сокольской (2012 г)

Романслар башкару белән танылган Юлия Җиһаншина 1812 елгы Ватан сугышына багышланган «Рус сугышчыларының җырлары» программасын тәкъдим итә (2012 ел)
Известная казанская исполнительница романсов – Юлия Зиганшина с программой «Песни русского воинства» К 200-летию Отечественной войны 1812 года. (2012 г)

Казанның танылган музыка белгече Георгий Канторның «Мәңгелек өчен яшәү» китабын тәкъдир итү кичәсе (2012 ел)
Презентация книги известного казанского музыковеда Георгия Кантора «Жизнь для вечности» (2012 г)

Музыка белгече Гүзәл Юнысова «Опера дөньясына сәяхәт» видеосалонында (2011ел)
Видеосалон «Путешествие в мир оперы» с музыковедом Гузель Юнусовой (2011 г)

Сәнгать бүлеге мөдире Т.Н. Рудик Опера яратучылар клубы президенты О.Г. Ильина белән «Музыка еллар ташкынында» музыкаль кунакханәсендә (2011 ел)
Заведующая отделом искусств Т.Н. Рудик с Президентом Клуба любителей оперы О.Г. Иглиной на Музыкальной гостиной «Музыка в потоке времени» (2011 г)

Татарстан Республикасы Рәссамнар берлеге әгъзасы Наилә Галәвиеваның «Туган йорт җылысы»дип аталган картиналар күргәзмәсен ачу (2012 ел)
Открытие выставки картин художницы, члена Союза художников РТ Наили Галявиевой «Тепло родного дома» (2012 г)

ды. Әлеге чараларда Мөнирә Булатова, Венера Ганиева, Галина Ластовка, Эдуард Трескин, Эмиль Җәләлетдинов, Юлия Җиһаншина, Леонид Любовский һәм башка күренекле сәнгать осталары канашты;

- Мәктәп укучылары һәм студентлар арасыннан күбрәк кешене китапханәгә җәлеп итү максаты белән Ачык ишекләр көннәре уздырыла. Мондый көннәрдә катнашучылар өчен китапханәнең төп бинасы буйлап экскурсия оештырыла. Бина төзелешенең романтик тарихы, диварлардагы, түшәмнәрдәге кабатланмас

Татарстан, которая производит ошеломляющее впечатление. Романтическая история строительства здания, роскошь и разнообразие интерьеров никого не оставляют равнодушным.

У отдела искусств нет своего концертного зала, но это не огорчает ни нас, ни наших пользователей, так как крупные мероприятия мы проводим в большом читальном зале На-

Татарстан Республикасы Рәссамнар берлеге әгъзасы Миләүшә Нуруллинаның «Чәчәкләр хакимлеге» дип исемләнгән картиналар күргәзмәсен тәкъдир итү (2012 ел)
Презентация выставки картин, художницы, члена Союза художников РТ М. Нуруллиной «Власть цветов» (2012 г)

бизәкләр, мәгарәгә охшатып ясалган уку залы, кыскасы, әлеге матурлык, нәфислек беркемне дә битараф калдыра алмый.

Сәнгать бүлегенең үз концерт залы юк, әмма бу хәл зур борчу тудырмый. Мөһим мәдәни чаралар ТР Милли китапханәсенең төп бинасындагы Зур уку залында үткәрелә. Биредәге искиткеч акустика һәм залның эчке бизәлеше шәһәрдәге бер генә бинада да юк.

Һәр ел саен бүлекнең мәдәни-агарту, мәгърифәтчелек эшендә яңа проектлар гамәлгә ашырыла, яңа алымнар кулланыла. Кушымтада 25 еллык бай тарихка ия сәнгать бүлеге тарафыннан үткәрелгән иң кызыклы чаралар теркәлгән.

Без зур канәгатьлек хисләре белән тарихыбызны барлыйбыз, чөнки аннан башка хәзерге тормышны алып бару һәм киләчәк турында хыяллану мөмкин түгел.

циональной библиотеки Республики Татарстан, замечательная акустика и великолепные интерьеры которого не имеют равных в городе.

Каждый год в просветительской работе отдела реализуются новые проекты, используются новые формы. В приложении представлена хроника наиболее интересных мероприятий отдела искусств за 25 лет ее существования.

Мы с удовольствием обращаемся к нашей истории, так как это помогает строить наше настоящее и воплощать мечты в будущем.

ТАТАРСТАН МИЛЛИ КИТАПХАНӘСЕ СӘНГАТЬ БҮЛЕГЕНЕҢ ИҢ ЯКТЫ СӘХИФӘЛӘРЕ:

■ **1987 ел** – татар музыкаль мәдәнияте легендасы, җырчы Мөнирә Булатова катнашында үткәрелгән музыкаль-тематик кичә;

■ **1988 ел** – Казандагы 10, 24, 42 нче һөнәри-техник белем бирү училищелары укучылары өчен грампластинкаларга үткәрелгән 17 күзәтү;

■ **1989 ел** – җырчы Галина Ластовка катнашында үткәрелгән романслар музыкаль-тематик кичәсе;

■ **1990 ел** – композитор Рәшит Кәлимуллинның «Камера ансамбльләре» грампластинкасы премьерасы;

■ **1991 ел** – Казан Дәүләт педагогика институты студентлары өчен, периодик басмалар бүлеге белән берлектә, «Матурлык белән очрашу» дигән сәнгать сөючеләр клубы оештырылды. 1991-1995 еллар проекты. Барлыгы 20 утырыш үткәрелде.

■ **1991 ел** – җырчы Венера Ганиеваның «Туй күлмәге» грампластинкасы премьерасы;

■ **1992 ел** – рәссам-модельер Тальмира Рөстәмова белән очрашу;

■ **1993 ел** – Разил Вәлиевнең «Бер алманы бишкә бүләек» китабы премьерасы (периодик басмалар бүлеге белән берлектә);

■ **1995 ел** – Леонид Любовскийның «Бах турында кечкенә генә китап» презентациясе;

■ **1995 ел** – күренекле татар композиторы Салих Сәйдәшевнең улы – Альфред Сәйдәшев катнашында истәлекләр кичәсе;

■ **1996 ел** – Александр Ключарев иҗатына багышланган «Халыклар дуслыгы җырчысы» дигән музыкаль-тематик кичә;

■ **1997 ел** – Франц Шубертның тууына 200 ел тулуга багышланган, композитор Рәшит Абдуллин катнашында үткәрелгән музыкаль-тематик кичә;

■ **1998 ел** – Татарстан укытучылар белемен күтәрү институты курсантлары (музыка һәм сынлы сәнгать укытучылары) өчен Мәгълүмат көннәре (1998-2010 еллар проекты);

■ **1999 ел** – Композитор Леонид Любовскийның «Борынгы көйләр» дип аталган ноталар җыентыгы презентациясе (виолончелистка Лариса Маслова катнашында);

■ **2000 ел** – «Опера дөньясына сәяхәт» видео-

ЯРКИЕ СТРАНИЦЫ ОТДЕЛА ИСКУССТВ НАЦИОНАЛЬНОЙ БИБЛИОТЕКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН:

■ **1987 год** – музыкально-тематический вечер с участием легенды татарской музыкальной культуры, певицы Муниры Булатовой;

■ **1988 год** – обзоры грампластинок для учащихся профессионально-технических училищ № 10, 24, 42 г. Казани (проведено 17 обзоров);

■ **1989 год** – музыкально-тематический вечер романсов с участием певицы Галины Ластовки;

■ **1990 год** – премьера грампластинки композитора Рашида Калимуллина «Камерные ансамбли»;

■ **1991 год** – Клуб любителей искусства «Встречи с прекрасным» для студентов Казанского государственного педагогического института (совместно с отделом периодических изданий). Проект 1991–1995 гг. Всего было проведено 20 заседаний;

■ **1991 год** – премьера грампластинки певицы Венеры Ганеевой «Свадебное платье»;

■ **1992 год** – встреча с художником-модельером Тальмирой Рустамовой;

■ **1993 год** – премьера книги Разиля Валеева «Бер алманы бишкә бүләек» (совместно с отделом периодических изданий)

■ **1995 год** – презентация книги Леонида Любовского «Маленькая книжечка о Бахе»;

■ **1995 год** – вечер воспоминаний о Салихе Сайдашеве с участием сына композитора Альфреда Сайдашева;

■ **1996 год** – музыкально–тематический вечер, посвященный творчеству Александра Ключарева «Певец дружбы народов»;

■ **1997 год** – музыкально–тематический вечер, посвященный 200–летию со дня рождения Франца Шуберта с участием композитора Рашида Абдуллина;

■ **1998 год** – Дни информации для учителей музыки и изобразительного искусства – курсантов Татарского института усовершенствования учителей (проект 1998–2010 гг.);

■ **1999 год** – презентация нотного сборника композитора Леонида Любовского «Старинные мотивы» с участием виолончелистки Ларисы Масловой;

салонының һәм «Музыка вакыт ташкынында» музыкаль кунакханәсенең эшли башлавы;

■ **2001 ел** – Казандагы гарипләр һәм ветераннар өчен реабилитацияләү үзәгендә ял итүчеләр өчен видео һәм аудио кассеталарга күзәтү (2001-2005 еллар проекты);

■ **2002 ел** – А. М. Горький исемендәге әдәби мемориаль музейда үткәрелә торган Шаляпин укуларының 10 еллыгы уңаеннан «Шаляпин укулары» китабын презентацияләү (Казан, 2002);

■ **2003 ел** – җырчы Эмиль Җәләлетдинов катнашында «Туган як моңнары» дигән музыкаль кичә;

■ **2004 ел** – музыка белгече Вадим Дулат-Алиев белән «Федор Шаляпинның онытылган партияләре» дигән очрашу кичәсе;

■ **2005 ел** – Казан музыка училищесы студентлары катнашында «Җырларда җырланган Казан» дигән музыкаль-тематик кичә;

■ **2006 ел** – Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең 70 еллыгына багышланган «Сез – безнең күңелләрдә» дигән музыкаль кичәләр циклы. Режиссеры һәм алып баручысы – Алмаз Хәмзин.

■ **2007 ел** – Сәнгать бүлегенең Ачык ишекләр көннәре «Татарстанның Бизнеска теләктәшлек итү институты» Идарә академиясенең 1 курс студентлары үтә торган гуманитар практика программасына кертелде.

■ **2007 ел** – Юлия Җиһаншина катнашында романслар кичәсе;

■ **2008 ел** – Китапханәләр көненә багышлап үткәрелә торган «Китапханәдә төн» дигән өч сәгатьлек, нон-стоп режимындагы мәдәни программа;

■ **2009 ел** – Эмиль Җәләлетдинов катнашында үткәрелгән «Татар музыкасының чишмә башы» дип исемләнгән музыкаль кичә;

■ **2010 ел** – милли диаспораларга хезмәт күрсәтүдә Халыклар дуслыгы йорты белән хезмәттәшлек итү (периодик басмалар бүлеге белән берлектә);

■ **2011 ел** – Татарстан Рәссамнар берлеге әгъзалары Наилә Галәвиеваның «Туган йорт җылысы» һәм Миләүшә Нуруллинаның «Чәчәкләр хакимлеге» картиналар күргәзмәләре;

■ **2011 ел** – «Гармония» психологик тренингы;

■ **2012 ел** – 1812 елгы Ватан сугышына багышланган чаралар циклы, шул исәптән Юлия Җиһаншина катнашында үткәрелгән «Рус сугышчыларының җырлары» дигән музыкаль кичә.

■ **2000 год** – начало работы видеосалона «Путешествие в мир оперы» и музыкальной гостиной «Музыка в потоке времени»;

■ **2001 год** – обзоры видео- и аудиокассет для отдыхающих Центра реабилитации инвалидов и ветеранов г. Казани (проект 2001–2005 гг.);

■ **2002 год** – презентация книги «Шаляпинские чтения» (Казань, 2002) к 10-летию проведения Шаляпинских чтений в литературно-мемориальном музее А.М. Горького;

■ **2003 год** – музыкальный вечер «Мелодии родного края» с участием певца Эмиля Заляльдинова;

■ **2004 год** – вечер-встреча с музыковедом Вадимом Дулат-Алеевым «Забытые партии Федора Шаляпина»;

■ **2005 год** – музыкально-тематический вечер «Казань в песнях» с участием студентов Казанского музыкального училища;

■ **2006 год** – цикл музыкальных вечеров «Мы вас помним», посвященный 70-летию Татарской государственной филармонии им. Г. Тукая. Режиссер и ведущий Алмаз Хамзин;

■ **2007 год** – Дни открытых дверей отдела искусств включены в Программу гуманитарной практики студентов 1 курса АУ «ТИСБИ»;

■ **2007 год** – вечер романсов с участием Юлии Зиганшиной;

■ **2008 год** – трехчасовая культурная программа ко Дню библиотек «Ночь в библиотеке» в режиме нон-стоп;

■ **2009 год** – музыкальный вечер «У истоков татарской музыки» с участием певца Эмиля Заляльдинова;

■ **2010 год** – сотрудничество с Домом дружбы народов в обслуживании национальных диаспор» (совместно с отделом периодических изданий);

■ **2011 год** – выставки картин членов Союза художников Республики Татарстан Наили Галявиевой «Тепло родного дома» и Миляуши Нуруллиной «Власть цветов»;

■ **2011 год** – психологический тренинг «Гармония»;

■ **2012 год** – цикл мероприятий, посвященных Отечественной войне 1812 года, в т. ч. музыкальный вечер «Песни русского воинства» с участием Юлии Зиганшиной.

Текст авторы: Т.Н. Рудик
Татарчага тәрҗемә: М.Х. Шакирова
Мөхәррирләре: А.Р. Габделхакова, И.Г.Һадиев
Редакция мөдире: Р.Ә. Хөсәенова
Дизайн һәм макетлау: А.Ф. Гаязов
Корректоры: Г.Ш. Шакирова
Техник мөхәррире: Г.Ә. Гамбәрова

Казан: «Милли китап» нәшрияты, 2012.

Автор текста: Т.Н. Рудик
Перевод на татарский язык: М.Х. Шакирова
Редакторы: А.Р. Абдулхакова, И.Г. Хадиев
Заведующая редакцией: Р.А. Хусаинова
Дизайн и верстка: А.Ф. Гаязов
Корректор: Г.Ш. Шакирова
Технический редактор: Г.А. Гамбарова

Казань: Издательство «Милли китап», 2012.